**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**«ЯҢА СУМАРОКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**III ЧАКЫРЫЛЫШ**

**КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ СЕССИЯСЕ**

**№ 1 КАРАР**

Яңа Сумароково авыл 2019 елның «11» ноябре

«Яңа Сумароково җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан
Бөгелмә муниципаль районы бюджетына
җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча
җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда
барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен
финанслашу максатларында субсидияләр бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә
Яңа Сумароково авыл җирлеге Советы
карар чыгарды:

1. «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Бөгелмә муниципаль районы бюджетына субсидияләр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Бөгелмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә (алга таба – субсидияләр).

2. Субсидияләр Чираттагы финанс елына һәм план чорына «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында Яңа Сумароково авыл җирлеге Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче - «Яңа Сумароково авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге башкарма комитеты.

4. Бөгелмә муниципаль районы бюджетына субсидияләрне бүлү Яңа Сумароково авыл җирлеге Советы тарафыннан чираттагы финанс елына һәм

план чорына «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында карар белән раслана.

5. Субсидияләр бирү максатлары һәм тәртибе «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты һәм Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты арасында төзелгән килешү нигезендә билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидиянең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы.

7. Килешүгә Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе һәм «Яңа Сумароково авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе кул куя.

8. Субсидияләр «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары исәбенә бирелә.

9. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын законнар нигезендә Бөгелмә муниципаль районының финанс органы контрольдә тота.

**Яңа Сумароково авыл җирлеге**
**башлыгы** **С.Л.Минханова**